КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1137

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 октябрь, 734 нче һәм 2017 ел, 28 август, 608 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән масштаблы инвестицион проектның критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү, Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территория-сендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү нияте булганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территория-сендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән билгеләнгән үзенчәлекләрдән чыгып гамәлгә ашырыла.»;

5 нче пунктның 8 нче пунктчасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) объектны урнаштыруны, проектны тормышка ашыруны финанслау мөмкинлеген раслый торган, шул исәптән объектны урнаштыру, проектны тормышка ашыру бәясенең кимендә 30 проценты күләмендә юридик затның үз акчасы (сәнәгать (индустрия) паркының идарәче компания өчен – сәнәгать (индустрия) паркы резидентлары проектында катнашучыларның үз акчалары) барлыгын раслый торган документлар (бизнес-план буенча).».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче; 2016 ел, 23 июнь, 433 нче; 2016 ел, 14 ноябрь, 840 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

әлеге карар белән расланган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү формасының 3.5 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.5.14 нче пунктча өстәргә:

«3.5.14. Алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү шартлары үтәлешен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Татарстан Республикасы Президенты адресына мөрәҗәгате нигезендә үткәрелә торган Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан уртак тикшерүне үткәрү өчен шартлар тудырырга.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия төзү хакында» 2016 ел, 16 апрель, 235 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 октябрь, 801 нче һәм 2017 ел, 2 июнь, 330 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Комиссия составына Азат Кыям улы Хамаевны – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин